

Һәр ел фасылынын vз матурлыгы бар. Ә мина ак тунлы кыш ошый. Чана-чангыда шуарга, кар атышып уйнарга, тәгәрәтеп, Кар бабай ясарга ярата торган идем. Ә кар кvп булса, уеннар тагын да кызыклырак. Биек таудан выжылдап очып тошәсен, бергәләшеп карда аунап аласын да, тирләп-пешеп оскә vрмәлисен, аннан тагын, тагын. Бер дә туйдырмый...

Менә шундый иде безнен кышкы каникуллар. Кадошкино районы Большие Поляны-Иса авылынын «Пунау» дигән биек тавыннан шуганда, трамплиннары белән бергә, чангы-лыжи ваткан кадәр... Я, булмаса, Раштуада берәрсенен атка жигә торган чанасын тауга алып тартып менәбез дә, шуна бергә утырышып авыл читенә менә житәм дигәнгә кадәр шуып тошә торган булдык.   Шул вакыт телевизор карау турында сvз дә булмый торган иде, ә компьютер-планшертлар ботенләй юк иде. Саулыклы балачак иде. Биек таудан выжылдап очып тошәсен, бергәләшеп карда аунап аласын да, тирләп-пешеп янадан оскә vрмәлисен, аннан тагын, тагын. Бер дә туйдырмый андый уеннар. Бияләйләр боз булып ката, битләр уттай яна, vзе шундый рәхәт!

Шулай, матурлыкка омтылучы авылым халкы, киләчәк буын турында кайгырып, балалары белән оныклары яна ел каникулларын матур vткәрсеннәр очен, шугалак-каток ясадык. Элек без каток та ясап тундыра идек, Иса елгасы бозында хоккей мәйданчыгы чистартып та уйнадык.

Авылнын мин яшәгән урамы ир-атлары, «Кызыл яр» дигән Гагарин исемен йорткән урам халкы, кем баласы, кем оныкларынын ял вакытын матур vткәрv, я булмаса, vз яшь чакларын искә алып, Иса елгасына кадәр шуып тошә торган шугалак ясап бирдек. «Сәламәт тәндә - сәламәт акыл» – дигән сvзләрне һәр кеше анлый. Бvгенге балалар экстрим дигән сvзне ярата; шуна биек тау кирәк аларга. Шулай, авыл халкы милкенә агач такталар, бруслар, кадак белән шерепләр сатып алынды, ә аннары матур иттереп шәһәрчә шугалак ясадык. Аны бергәләп Долотказин Булат Халил улы, Долотказин Илдан Ислям улы, Кильдеев Рәстәм Шәкир улы, Кильдеев Рәшит Фәрит улы, Долотказин Марат белән Руслан Альберт уллары ясадык. Мин дә ярдәм иттем.

Хисләр тагы да кискен булсын очен, карны Иса елгасына тошә торган юл буенча оеп, сулар сибеп тундырдык. Ниһаять, искитмәле каток барлыкка килде. Ин батырлары беренче буларак vзләренен салам тутырган капчыкка тvгел (элек без шулай шудык), ә сатып алынган шугалагына утырып жилдертте. Бу - Кызылъяр малай-кызлары! Ә башта

шугалакнын техник куркынычсызлыгын Долотказина Рәйсә тикшерде. Ул унышлы гына шугалактан жилдертеп шуып тоште, ә аннары бер-бер артлы балалар шуды; олылар да әллә кызыгып, әллә яшьлекләрен искә алып, ясаган катокларыннан Иса елгасына таба шуып алдылар. Алар тәгәри-тәгәри, тагы тора, тагы һәм тагы шудылар. Тирә-як урам малай-кызлары яна шугалакка рәхәтләнеп шуарга агылды. Сатып алынмаган шугалаклар-ледянкалар, тагы әллә-нинди исемле шугычлар сатылып алынды. Тирә-якта бала-чаганын чыр-чуы, шатлыклы колvләре еракларга  янгырады. Кvнелле каникуллар vтеп китте, ә шугалакта бvген дә бала-чага мәш килә.

**Равиль Казанбаев**